КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1278

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле архив белешмәләр, архив күчермәләре, архив өземтәләре, мәгълүмати хатлар бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 21 декабрь, 1016 нчы карары белән расланган «Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле архив белешмәләр, архив күчермәләре, архив өземтәләре, мәгълүмати хатлар бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле архив белешмәләр, архив күчермәләре, архив өземтәләре, мәгълүмати хатлар бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 21 декабрь, 1016 нчы карары белән расланган «Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле архив белешмәләр, архив күчермәләре, архив өземтәләре,

мәгълүмати хатлар бирү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартының 12 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты
үтәлмәү буенча шикаять бирү, аны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада Дәүләт архивына, КФҮ яки Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына бирелә.

Дәүләт архивы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына тапшырыла. КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр тиешле КФҮ җитәкчесенә бирелә. КФҮләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшырыла.

12.2. Дәүләт архивының, Дәүләт архивының вазыйфаи затының, Дәүләт архивы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, Дәүләт архивының рәсми сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан (www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

КФҮгә, КФҮ карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, КФҮ рәсми сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталыннан (www.gosuslugi.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Дәүләт архивына, КФҮгә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына кергән шикаять аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә Дәүләт архивы, КФҮ мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән опечаткалар һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә билгеләнгән срокны бозу очрагында шикаять - теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.5. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә һәм карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча карар кабул ителә, мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Дәүләт архивы, КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу

үтенә һәм дәүләт хезмәте алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгәндә, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

12.9. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин